Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Сарсак-Умга авыл җирлегенең Сарсак-Умга торак пунктында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның 9 декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлегенең Сарсак-Умга авылында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1. I төркем инвалидларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, 2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Сарсак-Умга территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган, 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Сарсак-Умга авылының Береговая һәм Логовая урамнарына илтүче тыкрыкларны төзекләндерү өчен вак таш сатып алу, җир катламы планировкасы һәм янгын пирсы төзү өчен вак таш балласты җәю;
- Сарсак-Умга авылы зиратын койма белән әйләндереп алу;
- авыл җирлеге чикләрендә кар чистарту;
- Сарсак-Умга авылы Ленин урамы буенча суүткәргеч өчен кое һәм кран урнаштыру

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Сарсак_Умга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы Т.С. НИКОЛАЕВА